**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**Сарманавылжирлеге**
**423350 Сарманавылы,**
**М.Жэлилур., 63**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E - mail: Sar.sar @ tatar.ru**
ИНН/КПП 1636001266/163601001

**Сармановское сельское поселение**
**САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**423350 с. Сарманово,**
**ул.М.Джалиля, 63**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E – mail: Sar.sar @ tatar.ru**
ИНН/КПП 1636001266/163601001

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

20 апреля 2022 года № 5

«Сарман муниципаль районының Сарман авыл җирлегендә гражданнардан сораштыру билгеләү һәм уздыру тәртибе турында» 2007 елның 31 маендагы 23 номерлы Сарман авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясы нигезендә Сарман авыл җирлеге Советы карар итте:

1. 2007 елның 31 маендагы 23 номерлы Совет карары белән расланган Сарман муниципаль районының Сарман авыл җирлегендә гражданнардан сораштыру билгеләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.Гражданнардан сораштыру билгеләү турындагы карар Сарман авыл җирлеге советы тарафыннан кабул ителә. Гражданнардан сораштыру өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://sarmanovo.tatarstan.ru веб-адрес буенча Сарман муниципаль берәмлегенең рәсми сайты файдаланылырга мөмкин.

Гражданнардан сораштыру билгеләү турындагы карарда түбәндәгеләр билгеләнә:

1) сораштыру уздыру датасы һәм сроклары;
2) сораштыру үткәргәндә тәкъдим ителә торган сорауны (сорауларны) формулировкалау;
3) сораштыру үткәрү методикасы;
4) сораштыру кәгазенең (сораштыру исемлегенең) формасы;
5) сораштыруда катнашучы муниципаль район халкының минималь саны.
6) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://sarmanovo.tatarstan.ru адресы буенча Сарман муниципаль берәмлегенең рәсми сайтыннан файдаланып гражданнардан сораштыру үткәрелгән очракта, сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе.

2) 22 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Сарман муниципаль районының Сарман авыл җирлеге бюджеты - җирле үзидарә органнары яки муниципаль район халкы инициативасы белән сораштыру уздырганда».

2. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында https://sarmanovo.tatarstan.ru. веб-адрес буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Сарман авыл җирлеге
Советы Рәисе Ф.М.Хөснуллин